**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ГАЙТӘН АВЫЛЫ СОВЕТЫ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**НУРЛАТСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН**
**СОВЕТ ГАЙТАНКИНСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

423014, РТ, Нурлат районы, Гайтән авылы, Үзәк урам, 1нче йорт
Тел. 8 (84345) 3-98-01

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«30» октябрь 2019 ел № 3

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Гайтән авыл җирлегенең Иске Авыл поселогында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Гайтән авыл җирлеге Уставының 23нче маддәсен гамәлгә ашыру максатында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының «Гайтән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2019 елның 16 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Гайтән авыл җирлегенең Иске Авыл поселогында Кыр урамы 2а йорты янында Кыр урамыннан1-59 нчы йортлардан үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын уздыруны билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Гайтән авыл җирлегенең Иске Авыл поселогы территориясендә яшәүче балигъ булган һәр кешедән, 1 гр инвалидтан тыш, балачак инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, 1000 сум сум күләмендә үзара салым акчасы кертергә һәм алынган акчаны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә ризамы?:

- Иске Авыл торак пунктында урам утлары системасы җиһазларын ремонтлау, яктырткычларны алыштыру һәм урнаштыру.

«ӘЙЕ» «ЮК».

3. Әлеге карарны «Интернет «мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (игълан итәргә), Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Гайтән авыл җирлегенең Иске Авыл поселогы мәгълүмат стендларында халык җыенын үткәрү датасына 10 көннән дә соңга калмыйча урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карар аның басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Гайтән авыл җирлеге башлыгы Н. В. Авдеева